**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.10.2022 № 1052

2022 елга һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 51 маддәсе нигезендә “Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында” 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм әлеге законга кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле мөлкәт хакының, шулай ук “Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге” коммерцияле булмаган партнерлык күрсәткечләренә нигезләнеп, Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгене билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм 2022 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының бусагасы:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен - 902 638,00 сум;

1.1.2. Ике кешелек гаилә өчен - 1 148 812,00 сум;

1.1.3. Өч кешелек гаилә өчен - 1 477 044,00 сум;

1.1.4. Дүрт кешелек гаилә өчен - 1 969 392,00 сум;

1.1.5. 5 кешедән торган гаилә өчен - 2 461 740,00 сум;

1.1.6. Алты кешелек гаилә өчен - 2 954 088,00 сум;

1.1.7.җиде кешелек гаилә өчен - 3 446 436,00 сум;

1.2. Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме бусагасы (ялгыз яшәүче граждан өчен):

1.2.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен - 21 630,00 сум;

1.2.2. Ике кешелек гаилә өчен - 13 764,00 сум;

1.2.3. Өч кеше һәм аннан да күбрәк кеше өчен - 11 798,00 сум.

2. Әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән күрсәткечләрне социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда кулланырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкчесе Р. М. Заһидуллин